КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 4 май г.Казань № 360

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2008 ел, 16 май, 327 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2008 ел, 16 май, 327 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 сентябрь, 830 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче пунктта «карарлары» сүзен «карары» сүзенә алыштырырга, «, Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 20 март, 150 нче» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.1 нче пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәт (биналар, урыннар, җир кишәрлекләре) исемлеге (исеме (җир кишәрлегенең кадастр саны), урнашу урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше (Россия Федерациясе Җир кодексының 7 статьясы нигезендә җир кишәрлеге категориясе һәм аннан рөхсәт ителгән файдалану), файдалануны чикләү, өченче затлар хокуклары белән чикләү);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин